РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.04.2026 Буа шәһәре №160/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2026-2027 елгы җылыту чорына әзерлек планын раслау турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон (27.10.2025 ел редакциясендә), Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык чорына әзерлекне тәэмин итү кагыйдәләрен һәм җылылык чорына әзерлекне тәэмин итүне бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» 2024 елның 13 ноябрендәге 2234 номерлы боерыгы нигезендә, үз вакытында әзерлек максатларында һәм 2026/2027 елгы җылыту чорын Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында тотрыклы уздыру өчен, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районының 2026/2027 елгы җылыту чорына әзерлек планын 1 нче кушымта нигезендә расларга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Р.Шакирҗанов

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы Башкарма
комитетының
«___» ___________ 2026елдан
______ номерлы карарына №1 кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2026/2027 елгы җылыту чорына әзерлек планы

| № т/б | Чаралар исеме | Башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1 | Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан көзге-кышкы чорга әзерлек эшләре планын раслау | 15.04.2026 кадәр |
| 2 | Җылылык энергиясен кулланучылар тарафыннан көзге-кышкы чорга әзерлек эшләре планын раслау | 30.04.2026 кадәр |
| 3 | Җылыту чорына әзерлекне тәэмин итү буенча комиссия төзү | 01.06.2026 кадәр |
| 4 | Җылыту чорына әзерлекне бәяләүне уздыру программасын эшләү, анда җылыту чорына әзерлекне бәяләргә тиешле затлар турында мәгълүмат, комиссия әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары тасвирламасы, әзерлекне бәяләүне уздыру сроклары һәм графигы һәм җылыту чорына әзерлек индексын исәпләү өчен бәяләү кәгазе | 15.08.2026 кадәр |
| 5 | «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта әзерлекне бәяләүне уздыру сроклары турында хәбәрнамә урнаштыру | әзерлекне бәяли башлаганчы 20 календарь көннән дә соңга калмыйча |
| 6 | Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның һәм идарәче оешмаларның җылылык чорына әзерлеген бәяләүне гамәлгә ашыру | 01.11.2026 кадәр . |
| 7 | Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар һәм җылылык энергиясен кулланучылар һәм идарәче оешмалар өчен җылылык чорына 2026-2027 еллар җылылык чорына әзерлекне тәэмин итүне бәяләүне үткәрү | әзерлекне тәэмин итүне бәяли башлаганнан соң 30 көн эчендә |
| 8 | Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар һәм җылылык энергиясен кулланучылар өчен 2026-2027 елларның җылыту чорына әзерлеген бәяләү актларын төзү | әзерлекне тәэмин итүне бәяләүне тәмамлау датасы белән бер эш көненнән дә соңга калмыйча |
| 9 | Җылылык энергиясен кулланучылар өчен 2026-2027 еллар җылыту чорына әзерлекне тәэмин итү паспортын бирү | 15.09.2026 елдан да соңармыйча |

| | | |
|---|---|---|
| 10 | Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар өчен 2026-2027 елларга җылыту чорына әзерлекне тәэмин итү паспортын бирү | 01.11.2026 елдан да соңармыйча |
| 11 | Муниципаль берәмлекнең 2026-2027 еллар җылыту чорына әзерлеген тәэмин итү паспортын алу. | 20.11.2026 елдан да соңармыйча |
| 12 | Тикшерелә торган затны, әзерлек дәрәҗәсен һәм әзерлек индексын күрсәтеп, әзерлекне тәэмин итүне бәяләү нәтиҗәләре турында җыелма мәгълүматны «Интернет»челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында бастырып чыгару | 01.11.2026кадәр |